УДК 811.512.145

*Б.К. Миңнуллин*

# XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ГАЗЕТАСЫ ҺӘМ ТАТАР МИЛЛИ ӘДӘБИ ТЕЛЕНЕҢ ФОРМАЛАШУЫ

В статье рассматриваются роль и место татарской периодической печати в истории формирования татарского национального литературного языка. В начале XX века на страницах татарской периодической печати велись споры о путях дальнейшего развития старотатарского языка. В данный период он функционировал в нескольких письменных вариантах, которые нашли отражение в том числе и в языке татарских газетных текстов.

**Ключевые слова:** литературный язык, татарский национальный литературный язык, языковая вариативность, татарская периодическая печать.

Билгеле булганча, XIV гасырдан башлап татар теле халык сөйләм теле кысаларында үсеш ала. Казан ханлыгының Рус дәүләтенә кушылуы нәтиҗәсендә, бүгенге урта диалект вәкилләренең ата-бабалары – Казан халкының бер өлеше Идел буенда көн күргән кыпчак кабиләләре белән кушылып, катнаш яшәү урыннары барлыкка китерәләр. Әлеге процесс нәтиҗәсендә, башка халыклардан аермалы буларак, Идел буе татарларында, капиталистик мөнәсәбәтләр урнашканчы ук, төп диалектларның характерлы үзенчәлекләрен үз эченә алган авыл гомумхалык сөйләмә теле, ягъни авыл койнесы барлыкка килә. Алга таба, капиталистик мөнәсәбәтләр ныгыган саен, илнең төп сәнәгать үзәкләре саналган Казан, Уфа, Екатеринбург, Пермь, Оренбург, Җаек, Троицк, Чиләбе шәһәрләрендә, татар теленең төрле диалектларында сөйләшүче авыл халкы күпләп күчеп килү белән бәйле рәвештә, татар шәһәр койнесы да формалаша. XX гасыр башларында исә, авыл һәм шәһәр койнелары нигезендә Идел буе татар милли әдәби теле барлыкка килә һәм халык сөйләмә теленә турыдан-туры йогынты ясый башлый [Закиев, 1995, с. 264]. Шул ук вакытта, татар милли әдәби теленең формалашуына XX гасыр башында барлыкка килгән татар вакытлы матбугаты да йогынты ясамый калмый. Милли телнең башлангыч формаларын XX гасыр башында дөнья күргән татар газета-журналларының телендә табарга мөмкин.

XX гасыр башына кадәр чын мәгънәсендә «татар газетасы» булган дип әйтү дөрес булмас. Әлбәттә, 1883–1918 елларда Бакчасарайда нәшер ителгән «Тәрҗемән», 1903–1905 елларда Тифлистә чыккан «Шәркый рус» газеталары күпмедер күләмдә татар халкының рухи ихтыяҗларын канәгатьләндергән. Ләкин әлеге газеталарның бөтен төрки-мөселман дөньясының, шул исәптән татар дөньясының формалашуына һәм үсешенә керткән өлешен исәпкә алган очракта да, XX гасыр башында Россиядә яшәүче татар халкы үз вакытлы

матбугатын булдыру өчен инде өлгереп җиткән була. 1905–1917 еллар арасында Россиянең Казан, Оренбург, Уфа, Петербург һ.б. шәһәрләрендә барлыгы 120 дән артык татар телле газета-журнал дөнья күрә. Шундыйлардан, мәсәлән, «Нур» (Санкт-Петербург, 1905–1914), «Вакыт» (Оренбург, 1906–1918), «Йолдыз» (Казан, 1906–1918), «Кояш» (Казан, 1912–1918), «Борһане тәрәккъый» (Әстерхан, 1906–1911) газеталарын һ.б.ны атап китәргә мөмкин.

Гомумән алганда, бу чорда татарлар арасында укымышлы халыкның саны югары булу сәбәпле, нәшриятчылык эше зур үсеш ала. Татар вакытлы матбугатының беренче үрнәкләре гарәп графикасында басыла һәм идеологик күзлектән чыгып караганда, ике яклап реакцион-клерикаль һәм революцион-радикаль агымнар белән чикләнгән киң бер аланны тәшкил итә. Хронологик планда XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты, югарыда әйтелгәнчә, 1905–1907 һәм 1917 елгы революцияләр арасындагы чорны алып тора. Шунысы мөһим, әлеге вакыт аралыгында басылган газета һәм журналлар укучыга тәкъдим ителгән тема һәм фикер төрлелеге ягыннан совет чоры татар вакытлы матбугатыннан күпкә баерак була. Әйтергә кирәк, татар газеталарының зур өлеше кыска гына вакыт эчендә басылып, юкка чыгалар, яисә башка исем астында чыгуларын дәвам итәләр. 1905–1908 елларда татар вакытлы матбугаты күтәрелеш чорын кичерсә, берничә ел үтүгә, хөкүмәт эзәрлекләве һәм цензура белән бәйле рәвештә, татар телендә чыгып килүче газета һәм журналларның саны кискен рәвештә кими башлый. Әлеге үзгәрешне беренче чиратта татар вакытлы матбугатының либераль һәм социал-демократик юнәлештәге вәкилләре тоя. Мәсәлән, 1905 елдан соң чыга башлаган һәм 1911 ел ахырында нәшер ителүен дәвам иткән либераль газета һәм журналлардан бары тик «Йолдыз» (Казан, 1906–1918), «Вакыт» (Оренбург, 1906–1918), «Шура» (Оренбург, 1908–1917) һәм «Идел» (Әстерхан, 1907–1914) басмаларын атап китәргә була.

XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты, идеологик планда капма-каршы ике агым вәкилләре – җәдитчеләр һәм кадимчеләр кулында җитди коралга әйләнә. XIX гасырның икенче яртысында, Россиядә буржуаз мөнәсәбәтләр урнашуга бәйле рәвештә, татар җәмгыятенең социаль-икътисади һәм рухи-идеологик тормышында барлыкка килгән үзгәрешләргә карата реакция буларак үсеп чыккан кадимчелек юнәлешенең татар вакытлы матбугатындагы төп өлгесе итеп «Дин вә мәгыйшәт» (Оренбург, 1906–1918) журналын атарга мөмкин. Кадимчеләр яклы булган әлеге иң консерватив һәм кискен-клерикаль дини, фәнни, әдәби һәм сәяси басманың нашире мулла Мөхәммәдвәли Хөсәенов була. Татар җәмгыятендә урнашкан идеологик кырның икенче ягында исә җәдитчелек агымын пропагандалаган милли-демократик юнәлештәге атналык

«Әлислах» (Казан, 1907–1909) газетасы урын ала. Рәсми нашире һәм мөхәррире Вафа Бәхтияров булган, ә чынлыкта бу вазифаны Габдулла Тукай белән Фатих Әмирхан үтәгән әлеге басма ике елдан азрак вакыт дәвамында гына чыгып калса да (барлыгы – 68 сан), татар җәмгыятендә милли үзаң, демократия, дөньяга яңа караш формалаштыруда эз калдыра.

География яктан чыгып карaганда, XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты киң территориядә дөнья күрә. Россиядә басылган беренче татар газетасы булып «Нур» газетасы (Санкт-Петербург, 1905–1914) санала. Ләкин, шуңа да карамастан, XX гасыр башы татар җәмгыятенең, шул исәптән татар вакытлы матбугатының үзәге Казан саналган. Казанда чыга башлаган беренче газета – «Казан мөхбире» (1905–1911). Аның рәсми нашире һәм мөхәррире Сәедгәрәй Алкин – адвокат, Казан губернасыннан Дәүләт думасының беренче чакырылыш депутаты, «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясенә нигез салучыларның берсе. «Казан мөхбире»нән соң берничә ай узуга Казанда «Йолдыз» (1906–1918), соңрак – «Азат» (1906, барлыгы – 56 сан) газеталары дөнья күрә. 1905 елда Җаекта «Фикер» (1905–1907), соңрак «Яңа тормыш» (1907–1908) газеталары басыла башлый. Петербургта «Өлфәт» (1905–1907), ә 1913 елда «Ил» (1913–1915) газеталары чыга башлый. 1914 елда «Ил» газетасы Мәскәүдә басыла башлый, «Сүз» (1915–1916), соңрак «Безнең ил» (1916–1917), ә 1917 елның 23 мартыннан янәдән «Ил» (1917–1918) исемнәре астында нәшер ителә. 1906 елда Оренбургта «Вакыт» (1906–1918), ә 1907 елда социал-демократик «Урал» (1907, барлыгы – 31 сан) газетасы, 1908 елда «Шура» (1908–1917) журналы чыга башлый. Әстерханда 1906 елда «Борһане тәрәкъкый» (1906–1911), 1907 елда «Ислах» (1907, барлыгы – 3 номер), «Хәмият» (1907–1908), «Идел» (1907–1914), «Мизан» (1908–1909) газеталары дөнья күрә. Уфада 1906 елда «Әлгаләмел ислами» (1906–1907), Самарада 1908 елда «Икътисад» (1908–1913) журналы басыла башлый.

XX гасыр башы татар вакытлы матбугатының һәрбер вәкиле, нашир һәм мөхәррирләрнең теләк-хуплауларына бәйле рәвештә, үзе үк әдәби телнең теге яки бу вариантын кулланылышка кертүче бер механизм ролен башкара. Шушы фикернең дәлиле итеп, XX гасыр башында татар вакытлы матбугаты битләрендә «Татар теле нинди булырга тиеш?» дигән сорауга багышланган бәхәсне китерергә мөмкин. Әлеге бәхәс, гомумән алганда, татар милли әдәби теле формалаштыруга зур өлеш кертә.

«Нур», «Фикер», «Йолдыз», «Шура» газета-журналларында барган тел бәхәсләренә карaганда, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәби теле берничә вариантта үсеш ала:

1. Әдәби тел – классик язма иске татар әдәби теленең традицияләрен дәвам итүче, гарәп-фарсы лексик һәм грамматик формалары белән баетылган вариант;

2. Җәдиди-госманлы – «Тәрҗеман» газетасының теленә якын булган вариант;

3. Татар сөйләмә теленең лексик һәм грамматик формалары белән баетылган вариант [Бәширова, 1999, б. 12].

Аңлашылганча, хөкүмәттән татар телендә вакытлы матбугат чыгаруга рөхсәт алу XX гасыр башы татар җәмгыяте өчен катлаулы мәсьәләләрнең берсе була. Газета һәм журналлар халык арасында киң таралыш тапсын өчен, аларның теле барлык социаль катламнарга да аңлаешлы булу зарурияте туа. Ләкин шул чорда яшәгән бер төркем шәхесләрнең фикеренә караганда, чыгып килүче газеталарның телен кистереп «татарча» дип әйтү дөреслеккә бик үк туры килеп бетми. XX гасыр татар вакытлы матбугаты теле яисә төрек теленә бик охшаш була, яисә татар әдәби теленең эшкәртелмәгән вариантын чагылдыра [Вәлиди, 2007, б. 159].

Милли интеллигенциянең бер өлеше газета теле итеп татар сөйләмә телен кулланырга өндәсә, икенче өлеше исә төрек теле нигезендә формалаштырылган вариантны тәкъдим итә. Вазгыятьне Төркиядә укып кайткан һәм мәдрәсәләрдә чор таләпләренә туры килгән «яңача» белем бирүче ярым-татарча, ярым-төрекчә сөйләшә торган яшь буын вәкилләре тагын да кискенләштерә. Шул рәвешле, «Тәрҗеман» үз битләрендә, барлык төрки халыкларны берләштерү максатын күз уңында тотып, госманлы төрекчәсенең гадиләштерелгән вариантын, «Нур» газетасы – катнаш татар-төрек вариантын, ә «Казан мөхбире» Казан татарлары телен куллана.

Мисал өчен XX гасыр башында нәшер ителгән «Вакыт» һәм «Йолдыз» газеталарын алыйк. «Вакыт» газетасы, үзенең якын кардәше «Шура» кебек үк, госманлы төрекчәсенә хас булган тел формаларын һәм татар теленең традицион байлыгын нигез итеп ала һәм татар халкының барлык социаль катламнарына да аңлаешлы булган сөйләм телен куллануга каршы була. Ә «Йолдыз» газетасы, киресенчә, төрек йогынтысыннан баш тарту юлына баса. Ягъни әлеге ике басманы чагыштырганда без өйрәнелгән чор өчен хас булган ике агым – төркичелек һәм татарчылык агымнарының вакытлы матбугат теленә карата каршылыклы юнәлешләре белән очрашабыз. Гомумән, «Йолдыз» газетасының телен шул ук чорда басылып килгән башка газеталар теле белән чагыштырганда, кискен аерма күзгә ташлана. Шунысы кызык, «Йолдыз» газетасының телендә, «Вакыт»тагы кебек үк, татар теленең традицион формалары чагылыш таба. Ләкин алар, «Вакыт» газетасының теленнән аермалы буларак, госманлы төрекчәсе белән янәшә түгел, ә бәлки әдәби телнең һәркемгә аңлаешлы булган варианты белән үрелеп бара [Вәлиди, 2007, б. 160].

Нәшер ителә башлаган дәверләрендә «Йолдыз» газетасы да, «Вакыт» та көндәлек басма булмый, алар атнасына өч тапкыр чыга. Шул сәбәпле һәрбер санның күпчелек текстлары басманың мөхәррирләре тарафыннан языла, ә читтән килгән текстлар

исә редакция хезмәткәрләре тарафыннан эшкәртелә. Газеталарның тел ягыннан булган аермалыклары, беренче чиратта, нәкъ менә әлеге факт белән бәйле булса кирәк. «Йолдыз»ның баштагы саннарында Һади Максудиның, «Вакыт»та Фатих Кәриминең каләме сизелә. Алга таба, газеталар көндәлеккә әйләнгәч, мәкаләләрне басмага әзерләү өчен бирелгән вакытның азаюы белән бәйле рәвештә, текст төрлелеге сизелә башлый, акрынлап газеталарның телендәге аерымлыклар кими һәм, ахыр чиктә, вакыт шаукымына буйсынып, алар да татарчылык агымы тәэсиренә эләгәләр. Ләкин шунысы үзенчәлекле, XX гасыр башында телдәге татарчылык һәм төркичелек агымнары өчен хас булган гарәп һәм фарсы тел формалары, нигездә бер-берсенә капма-каршы булган агымнарның уртак характерлы үзенчәлегенә әйләнә. Шул рәвешле, госманлы төрекчәсенә охшарга тырышкан «Вакыт» халык өчен, татарга якынрак булган, ләкин гарәп һәм фарсы тел формаларыннан кирәгеннән артык файдаланган «Йолдыз»га караганда, күпкә аңлаешлырак була. Ничек кенә булмасын, 1910 елдан соң милли интеллигенциянең бер өлеше «Вакыт»ның төркичелеге, «Йолдызның» «татарчылыгы»на каршы татар халкының барлык социаль катламнарына да аңлаешлы булган татар сөйләмә телен куя. Вакытлы матбугатның татар сөйләмә теленә нигезләнгән вариантын без, мәсәлән, «Кояш» газетасы текстларында күрә алабыз.

Әйтеп үтелгәнчә, татар вакытлы матбугатының барлыкка килүе һәм үсеше белән татар милли әдәби теленең формалашуы арасында билгеле бер бәйләнеш бар. Җәмгыятьнең сәяси, мәдәни һәм рухи тормышында зур үзгәрешләр вәгъдә иткән XX гасыр башында, милли әдәбият белән беррәттән, татар вакытлы матбугаты да теге яки бу телнең камиллеген күрсәтүче төп фактор – милли әдәби телне булдыруда ярдәм итәрлек корал ролен үти. Милли әдәби телнең нигезе булырдай тел вариантлары нәкъ менә 1905–1907 һәм 1917 елгы революцияләр арасындагы чорда дөнья күргән татар вакытлы матбугаты битләрендә чагылыш таба, сайлап алу процессын кичерә.

**Әдәбият**

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле тарихы: XIX гасыр ахыры – XX йөз башы. Казан: Казан дәүләт технология университеты нәшрияты, 1999. 528 б.

*Вәлиди Җ.* Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. 271 б.

*Закиев М.З.* Татары: проблемы истории и языка. Сб. статей. Казань, 1995. 464 с.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителде*

***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге мөдире*